**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2024елның15 ноябре 287№

2025нче елга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы милкендә
торучы мөлкәтне хосусыйлаштыруның
фаразлау планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 маддәләре, 85 маддәсендәге 4 п. 8 п., 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. МКО «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы»на 2025 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразланган планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат портал»ында һәм Россия Федерациясенең www.torgi.gov.ru рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанс, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль
районы Башлыгы А. Ф. Никошин

2024нче елның15нче
ноябрендәге
Әлки муниципаль районы
Советының
287нче№ карарына
1нче кушымта

**2025нче елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә торучы мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)**

**1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. 2025нче елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә торучы мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы(программасы), 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 маддәләре, 85 маддәсендәге 4 п. 8 п., 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2025 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга, күчемсез милек объектларын карап тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ Федераль законы нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

**2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт.**

2.1. 2025 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль казнадагы һәм Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар файдалануында булмаган муниципаль мөлкәт

2.2. Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге:

| № п/п | Мөлкәт атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру (чыгару) елы | Хосусыйлаштыруның күздә тотыла торган срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Автотранспорт чарасы<br>FORD ФОРД «ФОКУС»<br>Теркәлү номеры<br>Т 359 ОС 116 RUS<br>VIN X9FVXXEEBMDD54314 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Базарлы Матак авылы,<br>Крайнов ур, 56нчы йорт | 2013 | 1 квартал |
| 2. | Автотранспорт чарасы<br>TOYOTA LAND CRUISER 200<br>Теркәлү номеры<br>Р 226 КО 116 RUS<br>VINJTMHT05J105027464 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Базарлы Матак авылы,<br>Крайнов ур, 56нчы йорт | 2008 | 2 квартал |
| 3. | Автотранспорт чарасы<br>LADA 212140 LADA 4X4<br>Теркәлү номеры<br>Р 894 ХО 116<br>VIN XTA212140D2140552 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Базарлы Матак авылы,<br>Совет ур., 11нче йорт | 2013 | 1 квартал |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Автотранспорт чарасы<br>FORDEXPLORER<br>Теркәлү номеры<br>В 876 НМ 716<br>VIN Z6FBXXESWBFC27318 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Югары Колчурино авылы<br>8 Март ур., 21нче йорт | 2015 | 3 квартал |
| 5. | Автобус<br>ФИАТ ДУКАТО<br>Теркәлү номеры<br>ВТ 328 16<br>VINZ7G244000AS012610 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Базарлы Матак авылы,<br>Крайнов ур., 56нчы йорт | 2009 | 1 квартал |
| 6. | Автобус<br>ПАЗ-32053-70<br>Теркәлү номеры<br>Р 029 СУ 16 RUS<br>VINX1M3205CX80008724 | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Иске Матак авылы,<br>Пролетар ур., 11нче йорт | 2008 | 2 квартал |
| 7. | Торак булмаган бина, 1катлы . кирпеч,<br>гомуми мәйданы – 301,9кв.м. | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Иске Салман авылы,<br>Үзәк ур., 6нчы йорт | 1973 | 3 квартал |
| 8. | Мөлкәт комплексы:<br>- Хлебодар башл.мәктәп бинасы, 2катлы, кирпеч, гомуми мәйданы – 1128,4кв.м., 2003нче елда төзелгән;<br>-Мәктәп котелнясы, мәйдан-38,4 кв.м., 2003нче елда тозелгән;<br>- Хуҗалык төзелеше,<br>мәйданы – 27,4кв.м, 2006нчы елда төзелгән | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Хлебодаровка авылы,<br>Яшел ур., 2нче йорт | | 3 квартал |
| 9. | Мөлкәт комплексы:<br>- Мәктәп бинасы, 2 катлы, кирпеч, мәйданы – 1257,3кв.м, 1981нчы елда тозелгән;<br>- Котельня, мәйданы – 52,7кв.м, 2002 нче елда төзелгән | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Татар Чиябашы авылы,<br>Җиңү ур.,18нче йорт | 2002 | 4 квартал |
| 10. | Торак булмаган бина, кирпеч, гомуми мәйданы-198,4 кв.м. | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Татар Чиябаш авылы,<br>Җиңү ур., 25нче йорт | 1998 | 4 квартал |
| 11. | Күчемсез милек<br>Мөлкәт составы:<br>- Балалар бакчасы, билгеләнеше: торак булмаган, 1 катлы,<br>Шул исәптән җир асты - 0<br>- Җир участогы,җирләр категориясе : торак пунктларның җирләре, файдалануга рөхсәт ителгән: балалар бакчасы | Татарстан Республикасы,<br>Әлки районы,<br>Борискино авылы,<br>Яшьләр ур., 46нчы йорт | 1988 | 2 квартал |

**3 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

3.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге фаразлау планын үтәү барышында рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш башка массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.